РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноябрь 2021 ел г. Альметьевск № 1565

2022 елга Әлмәт муниципаль районы
балаларына туристлык-туган якны өйрәнү,
экология-биология, хәрби-патриотик,
социаль-педагогик, социаль-икътисадый,
табигый-фәнни, техник һәм культурология
юнәлешендәге өстәмә белем бирә торган
мәгариф учреждениеләренең
һәм өстәмә белем бирә торган күппрофильле
мәгариф учреждениеләренең норматив
чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик- туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләрен һәм өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм Әлмәт муниципаль районы уставы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга расларга:

Әлмәт муниципаль районы балаларына туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләренең һәм өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнары (1 нче кушымта);

балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирә торган мәгариф

Зак. № 305-2000

учреждениеләрендә һәм балаларга өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләрендә 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмәләр коэффициенты.

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга Әлмәт муниципаль районы балаларына туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләренең һәм Әлмәт муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге карарын 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирә торган учреждениеләрен финанслау;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — А.Н. Подовалов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
« 2 » ноябрь 2021 ел № 1565
карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы балаларына туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирә торган мәгариф учреждениеләренең һәм өстәмә белем бирә торган күппрофильле мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнары

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | 1 укучыга елына норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы елларда уку елы |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| экология-биология | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева